**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2017 Балык Бистәсе штп. № 19пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

Россия Пенсия фондының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы идарәсенең тәкъдимен карап, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2017 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»2017 елның 26 гыйнварындагы №88 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы уставының 46 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5277,28 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.2017 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5562,25 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә (№1,2 кушымта).

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»30.12.2015 ел, №360пи карарын 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5.Әлеге карарны Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда кабул итү: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Р. Х. Хәбибуллин

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
01.02.2017 № 19пи карарына
кушымта№1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2017 елның 1 февраленнән җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1560 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 843 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) ) | 3159,25 |
| Барлыгы: | 5562,25 |

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
01.02.2017 № 19пи карарына
кушымта№2

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2017 елның 1 февраленнән җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәрхүмне киендерү | 422 |
| 3.Табут бирү | 1138 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 843 |
| 5. Җирләү (каберләрне юу һәм күмү) | 3159,25 |
| Барлыгы | 5562,25 |